| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 20.03.2020 | Баулы шәһәре | № 254 |

Баулы муниципаль районы Советының
2019 елның 12 декабрендә кабул ителгән
238нче номерлы «Баулы муниципаль
районының 2020 елга һәм 2021 һәм
2022 еллар план чорына бюджеты
турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Баулы муниципаль районы Советының 2019 елның 12 декабрендә кабул ителгән 238нче номерлы «Баулы муниципаль районының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджеты турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 1 пунктындагы 1, 2, 3 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Баулы муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми кереме күләме 869 250,6 мең сум;

2) Баулы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 879 900,5 мең сум;

3) Баулы муниципаль районы бюджеты дефициты 10649,9 мең сум күләмендә».

1, 2, 6, 7, 14 номерлы кушымталардагы 1нче таблицаларны 1, 2, 3, 4, 5 кушымталар нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы рәисе

Р.Х. Гатиятуллин